КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 09 апрель г.Казань № 378

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2025 ел, 20 май, 339 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2025 ел, 20 май, 339 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

өченче абзацка «, товар үгезләрен» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацка «сыерлар,» сүзеннән соң «ана сарыклар һәм саулык бәрәннәр,» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта «2025 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

5 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

«, субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

55 пунктның икенче абзацында «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

60 пунктта «Бирелгән субсидияләр» сүзләрен «Субсидия акчалары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сату өчен билгеләнгән һәм нәселле булган кысыр таналар һәм тана сыерлар сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исеменә «, товар үгезләрен» сүзләрен өстәргә;

1 пунктка «беренче бозаулаучы» сүзләреннән соң « һәм (яки) товар үгезләре» сүзләрен өстәргә;

4 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

«, субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидия түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

товар һәм (яисә) нәселле таналар һәм (яисә) беренче бозаулаучыларны сатып алганда:

юридик зат статусына ия һәм әлеге продукцияне турыдан-туры җитештерүчеләр булган авыл хуҗалыгы оешмаларыннан алынган;

сатып алынган таналарның яше 21 айдан 26 айга кадәр тәшкил итә, тере авырлыгы кимендә 430 килограмм һәм (яисә) беренче бозаулаганнарның яше - 27 айдан 36 айга кадәр, тере авырлыгы кимендә 450 килограмм;

нәселле таналар һәм (яисә) беренче бозаулаганнар саны нәсел заводларыннан һәм дәүләт нәсел регистрында теркәлү турында таныклыкка ия нәсел репродукторларыннан сатып алынган;

товар үгезләре сатып алганда:

юридик зат статусына ия булган авыл хуҗалыгы оешмаларыннан алынган;

сатып алынган товар үгезләренең яше алты айдан да артмый.»;

11 пунктка « һәм (яки) товар үгезләре» сүзләрен өстәргә;

12 пунктта:

беренче абзацка «беренче бозаулаучы» сүзләреннән соң « һәм (яки) товар үгезләре» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«W = N_1 \times S_1 + N_2 \times S_2 + N_3 \times S_3,»;$$

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$N_3$ - шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан тарафыннан сатып алынган товар үгезләре саны, баш;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«$S_3$ – бер баш товар үгезе өчен 35,0 мең сум исәбеннән субсидия ставкасы, әмма сатып алу бәясенең 50 проценттан артыгы түгел.

Субсидия күләмен исәпләгәндә, товарл һәм нәселле таналарның, һәм (яисә) беренче бозаулаганнарның, һәм (яисә) товар үгезләренең баш саны бер шәхси ярдәмче хуҗалыкка 15 баштан артмаска тиеш.»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Субсидия бирү нәтиҗәләре түбәндәгеләр:

сатып алынган товар һәм нәселле таналарны һәм (яисә) беренче бозаулаганнарны субсидия алган көннән алып биш ел дәвамында саклап калу, баш;

сатып алынган товар үгезләрен субсидияләр алган көннән алып өч ел дәвамында саклап калу, баш.»;

23 пунктта:

өченче абзацка «беренче бозаулаучы» сүзләреннән соң «һәм (яки) товар үгезләре» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацка «беренче бозаулаучы» сүзләреннән соң «һәм (яки) товар үгезләре» сүзләрен өстәргә;

54 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идарәләр үз шәхси счетына бюджет акчасы кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә субсидияләрне аларны алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында ачылган счетларына күчерә.»;

59 пунктта:

беренче абзацка «Бирелгән субсидияләр» сүзләрен «Субсидия акчалары» сүзләренә алмаштырырга;

татарча текста икенче абзацка «кире кайтару» сүзләренә кадәр «чараларын» сүзен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга өч яшьтән өлкәнрәк бияләр асрау чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

4 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

«, субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

6 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«агымдагы елда «Хорриот» ветеринария өлкәсендә Федераль дәүләт мәгълүмат системасында теркәлгән өч яшьтән өлкәнрәк бияләргә карата йогышлы һәм аеруча куркыныч авыруларга каршы вакцинация үткәрү.»;

46 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идарәләр үз шәхси счетына бюджет акчасы кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә субсидияләрне аларны алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында ачылган счетларына күчерә.»;

50 пунктта «Бирелгән субсидия тиеш» сүзләрен «Субсидия акчалары тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак булган кәҗә бәтиләрен асрау чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исеменә «сыерлар,» сүзеннән соң «ана сарыклар һәм саулык бәрәннәр,» сүзләрен өстәргә;

1 пунктның беренче абзацына «сыерлар,» сүзеннән соң «ана сарыклар һәм саулык бәрәннәр,» сүзләрен өстәргә;

4 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

«, субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

6 пунктта:

бишенче абзацка «сыерлар,» сүзеннән соң «ана сарыклар һәм саулык бәрәннәр,» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

агымдагы финанс елда «Хорриот» ветеринария өлкәсендә Федераль дәүләт мәгълүмат системасында теркәлгән савым сыерларына карата мәҗбүри дәвалау-профилактика чараларын үткәрү.»;

11 пунктка «сыерлар,» сүзеннән соң «ана сарыклар һәм саулык бәрәннәр,» сүзләрен өстәргә;

12 пунктта:

икенче абзацка «сыерлар,» сүзеннән соң «ана сарыклар һәм саулык бәрәннәр,» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«W = N_1 \times S_1 + N_2 \times S_2 + N_3 \times S_3,»;$$

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«$N_3$ – субсидия ставкасы бер ана баш сарыкка яки саулык бәрәнгә 1 000,0 сумнан исәпләнә;

$S_3$ – субсидия бирү елның 1 гыйнварына электрон хуҗалык кенәгәсе нигезендә торышы буенча шәхси ярдәмче хуҗалыкта ана баш сарыклар һәм саулык бәрәннәр саны, баш.»;

13 пунктка «сыерлар,» сүзеннән соң «ана сарыклар һәм саулык бәрәннәр,» сүзләрен өстәргә;

23 пунктның тугызынчы абзацына «сыерлар,» сүзеннән соң «ана сарыклар һәм саулык бәрәннәр,» сүзләрен өстәргә;

46 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идарәләр үз шәхси счетына бюджет акчасы кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә субсидияләрне аларны алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында ачылган счетларына күчерә.»;

50 пунктта «Бирелгән субсидия тиеш» сүзләрен «Субсидия акчалары тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2025 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга яшь кош-корт сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә «2025 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «2025 елда» сүзләрен төшереп калдырырга, «2025» саннарын «агымдагы» сүзенә алмаштырырга;

4 пунктта:

«Бюджет» бүлегендә» сүзләрен «(бердәм портал бүлегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

«, субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

12 пунктның беренче абзацында «2025 елда» сүзләрен «агымдагы елда» сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктның өченче абзацында «2025 елда» сүзләрен «агымдагы елда» сүзләренә алмаштырырга;

46 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идарәләр үз шәхси счетына бюджет акчасы кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә субсидияләрне аларны алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында ачылган счетларына күчерә.»;

50 пунктта «Бирелгән субсидия тиеш» сүзләрен «Субсидия акчалары тиеш» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин